| Республика Татарстан<br>Совет Кавзияковского сельского поселения Сармановского муниципального района | Татарстан Республикасы<br>Сарман муниципаль районы<br>Кәүҗияк авыл җирлеге Советы |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

31 март 2026 ел № 23

Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында»11.11.2014 ел, № 15 карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының (закон актларының аерым нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында» 2025 елның 28 ноябрендәге 425-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 130 пункты, Сарман муниципаль районы «Кәүҗияк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлеге советы карар итте:

1. Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 11.11.2014 ел, № 15 карарына (20.10.2015 ел, №7, 21.06.2018 ел, № 9, 19.11.2018 ел, № 24, 18.03.2020 ел, № 3, 02.11.2024 № 12, 22.11.2024 №18а, 16.12.2025 № 9, 30.12.2025 № 17, карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

«2 пунктның 2.4.3 пунктчасында «, проектлана торган, билгеләнеше күпфатирлы йорт булган, төзелеп бетмәгән объектлардан тыш»сүзләрен өстәргә;».

2. Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлеге Советының 20.02.2026 ел, № 22 «Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлеге Советының 11.11.2014 ел, № 15 «физик затлар мөлкәтенә салым турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында» карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз көченә керә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында халыкка җиткерергә (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының рәсми сайтында Интернетны мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Сарман муниципаль районы
Кәүҗияк авыл җирлеге Советы Рәисе Ф.Ә.Хөснетдинов